**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Яңа Кади авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Яңа Кади авыл җирлеге составына керүче Утыз Имән авылы торак пунктында

**25 октябрь 2024 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2025 елда Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлегенең Утыз Имән авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш.

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** ( юл кырыйларын чабу, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, триммерлар сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу), Утыз Имән торак пунктында югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- **Утыз Имән торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен башка билгеләнештәге җиһазларны ремонтлау** (Утыз Имән торак пунктында урамнарны яктырту яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру)

- **җир асты сулары чыга торган урыннарны (чишмәләрне) төзекләндерү** («Чәчәкле алан» чишмәсе территориясен төзекләндерү; үсентеләр сатып алу, аларны карау; Утыз Имән торак пунктында буяулар сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);

**- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Утыз Имән торак пунктындагы Гыйрфанов урамы буенча 100 метрлы 5 нче зиратка кадәр урам-юл челтәрен салу өчен 29-40 мм фракция вак ташы сатып алу).

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлегенең рәсми сайтында

Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Яңа Кади авыл җирлеге башлыгы М.М.Әминов